5) 97 статьяның 4 пунктындагы өченче абзацта «элек үзләренә бирелгән бюджет чыгымнары турында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторы билгеләгән тәртиптә һәм Татарстан Республикасы бюджетына күрсәтелгән акчалар кергән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырылган хисап нигезендә гамәлгә ашырыла» сүзләрен «финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән бюджетара трансфертлардан гыйбарәт тиешле бюджет чыгымнары турында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторы билгеләгән тәртиптә төзелгән һәм тапшырылган хисапка нигезләнеп, күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

6) 101 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацта «исемлеге» сүзеннән соң «, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары, контроль объектларының (аларның вазыйфаи затларының) хокуклары һәм бурычлары, шул исәптән аларның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының вазыйфаи затлары үткәрә торган тикшерүләрне, ревизияләрне һәм тикшеренүләрне оештыру ягыннан һәм техник яктан тәэмин итү буенча хокуклары һәм бурычлары» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (II өлеш) «2017 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2018 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $18^1$ статьясы нигезләмәләре, 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 13-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 164. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы» сүзләрен «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгеләүче яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын бозган өчен җаваплылык билгеләүче, элек билгеләнгәнен үзгәртүче яисә юкка чыгаручы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 статья. **Норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясау**

1. Норматив хокукый актлар проектларына әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла торган җайга салу йогынтысын бәяләү уздырылырга тиеш, моңа түбәндәгеләр керми:

а) региональ салымнарны, шулай ук федераль салымнар буенча салым ставкаларын билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы Татарстан Республикасы законнары проектлары;

б) бюджетка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы Татарстан Республикасы законнары проектлары.

2. Норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм Татарстан Республикасы бюджетының нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

3. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый актларга, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә экспертиза ясалырга тиеш.»;

3) 5 статьяда:

а) исемдә «Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә «Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы» сүзләрен «Әлеге Закон нигезендә җайга салу йогынтысын бәяләү уздырылырга тиешле» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 14-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 165. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«28 статья. **Күзәтчелекне һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру**

Вөҗдан иреге, дин тоту иреге турындагы һәм дини берләшмәләр хакындагы законнар үтәлешенә күзәтчелек итү һәм аны тикшереп тору федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 15-ТРЗ

## 166. «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2008 елның 13 октябрендәге 105-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның тугызынчы абзацында «2 өлешенең 62, 63 пунктлары» сүзләрен «2 пунктының 62, 63 пунктчалары» сүзләренә, «белгечләр әзерләү, аларны яңадан укыту һәм аларның квалификациясен күтәрү» сүзләрен «белгечләргә һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 статьяда «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 16-ТРЗ





## 167. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 пунктында «спорт клублары,» сүзләреннән соң «физкультура-спорт клублары һәм аларның берләшмәләре,» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяның 1 өлешендә:
а) 3 пунктның «б» пунктчасында «спорт чараларының» сүзләреннән соң «, шул исәптән «Хезмәткә һәм спортка әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (алга таба – ГТО комплексы) гамәлгә ашыру буенча физкультура чараларын һәм спорт чараларын үз эченә алганнарның» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:
«$3^1$) коммерциягә карамаган оешмаларга ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүне бәяләү хокукы бирү;»;

3) түбәндәге эчтәлекле $22^1$ статья өстәргә:
«$22^1$ статья. **ГТО комплексы. Төп эшчәнлекләре ГТО комплексын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән физкультура-спорт клублары һәм аларның берләшмәләре**

ГТО комплексын гамәлгә ашыру, ГТО комплексын гамәлгә ашыра торган физкультура-спорт клублары һәм аларның берләшмәләре эшчәнлеген оештыру Федераль закон нигезендә башкарыла.»;

4) 28 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$) ГТО комплексын гамәлгә ашыру өчен Федераль закон нигезендә шартлар тудыру;»;

5) 29 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29 статья. **Физик культураны һәм спортны медицина ягыннан тәэмин итү**

1. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларны медицина ягыннан тәэмин итүгә түбәндәгеләр керә:

1) шушы затларның сәламәтлеге торышын системалы рәвештә тикшереп тору;

2) шушы затларга физик йөкләнешләрнең сәламәтлекләре торышына туры килүен бәяләү;

3) шушы затларның авыруларын профилактикалау һәм дәвалау, алар алган җәрәхәтләрне дәвалау, аларны медицина ягыннан реабилитацияләү;

4) аларның сәламәтлеген физик культура һәм спорт белән шөгыльләнгәндә кулланыла торган чаралар һәм ысуллар ярдәмендә торгызу.

2. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә теләүче затны спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган оешмага, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен башка оешмага кабул итү һәм (яисә) аңа ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүгә рөхсәт бирү әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә медицина тикшерүе үтүне раслый торган документлар булганда гына гамәлгә ашырыла.

3. Физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыручылар аларда катнашучыларны медицина ярдәме белән тәэмин итәргә тиеш.

4. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибе (шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әзерләгәндә һәм үткәргәндә) сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функциясен башкара торган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә, моңа оешмаларда спорт әзерлеге үтәргә, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә һәм (яисә) ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәргә теләгән затларга медицина тикшерүен үткәрү тәртибе дә керә.



5. Чит дәүләтләрдә медицина яисә фармацевтика белеме алган һәм чит дәүләтләрнең физкультура-спорт оешмалары тарафыннан медицина белгечләре сыйфатында тәкъдим ителгән затлар Татарстан Республикасында рәсми физкультура чаралары һәм спорт чаралары үткәрелү чорында бу чит дәүләтләрнең физкультура-спорт оешмалары вәкилләренә, рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларга рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыручылар билгеләгән территорияләрдә медицина ярдәме күрсәтүне медицина яисә фармацевтика эшчәнлеген гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе законнарында каралган рөхсәт алу процедурасын үтмичә генә башкару хокукына ия.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 17-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 168. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы

Җыелма басмасы, 1993, № 11 — 12; 1994, № 1 — 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) беренче өлештә «янгыннарга каршы көрәшкә» сүзләрен «янгыннарны кисәтүгә, аларны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруга» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) янгыннарны кисәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру.»;

2) 4 статьяның җиденче абзацында «янгыннарга каршы көрәштә» сүзләрен «янгыннарны кисәтүдә һәм аларга каршы көрәштә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:

«Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итүне оештыру һәм янгыннан саклану эшчәнлеген координацияләү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4) 19 статьяда:

а) җиденче өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгыннан саклану бүлекчәләренең көчләре, җәлеп ителгән көчләр һәм бердәм дәүләт гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү системасы чаралары белән янгыннарны сүндергәндә һәм һәлакәттән коткару эшләрен гамәлгә ашырганда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, мөлкәтне коткару буенча, шул исәптән түбәндәге кирәкле гамәлләр башкарыла:»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«янгыннарның куркыныч факторлары, һәлакәтләрнең куркыныч чагылышлары йогынтысындагы зоналарда булган оешмалар хезмәткәрләренең һәм аларның территорияләрендәге башка гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә зыян килү куркынычы булса, әлеге оешмаларның эшчәнлеген туктатып тору.»;

б) унынчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгын сүндерү җитәкчесе янгын зонасын билгели, янгын сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару гамәлләре үткәрелә торган территория чикләрен, күрсәтелгән гамәлләрне башкару тәртибен һәм үзенчәлекләрен билгели, кешеләрне һәм мөлкәтне коткару, кирәк булганда, янгынны сүндерүгә өстәмә



көчләрне һәм чараларны, шул исәптән бердәм дәүләт гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү системасы чараларын җәлеп итү турында карар кабул итә, янгын урынында янгыннан саклану бүлекчәләренең һәм янгын сүндерүгә җәлеп ителгән көчләрнең гамәлләре белән идарә итү тәртибен билгели, янгын урынында килүче көчләрне һәм чараларны урнаштыра, янгын зонасында янгын сүндерүдә катнашучылар һәм янгын сүндерүгә, һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга җәлеп ителгән көчләр белән элемтәне оештыра, алга таба янгын чыгу сәбәбен билгеләү өчен янгын урынында әйберләр рәвешендәге дәлилләрне, мөлкәтне һәм әйберләрнең урнашу тәртибен саклау чараларын күрә. Кирәк очракта янгын сүндерү җитәкчесе башка карарлар, шул исәптән күрсәтелгән территориядә вазыйфаи затларның һәм гражданнарның хокукларын чикли торган карарлар да кабул итә.»;

5) 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 статья. **Янгынга каршы пропаганда һәм янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү**

Янгынга каршы пропаганда массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус әдәбият һәм реклама продукциясе бастыру һәм тарату, тематик күргәзмәләр, смотрлар, конференцияләр ярдәмендә һәм халыкка мәгълүмат бирүнең Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка рәвешләреннән файдаланып гамәлгә ашырыла. Янгынга каршы пропаганданы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимиятнең янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле органы, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар үткәрә.

Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү янгынга каршы инструктаж һәм (яисә) янгынтехник минимумы программалары буенча башкарыла.

Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү тәртибе, төрләре, сроклары, шулай ук һөнәри белем бирү программалары эчтәлегенә карата таләпләр, программаларны раслау һәм килештерү тәртибе федераль башкарма хакимиятнең янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

Гамәлгә ашырыла торган программа төренә карап, оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү турыдан-туры эш урынында һәм (яисә) мәгариф эшчәнлеген башкаручы оешмаларда үткәрелә.

Мәгариф оешмаларында белем алучыларны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү мәҗбүри үткәрелә. Мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы органнар һәм янгыннан

саклану хезмәте ирекле яшь янгын сүндерүчеләр дружиналары төзергә мөмкин. Ирекле яшь янгын сүндерүчеләр дружиналары төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 18-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 169. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа унберенче абзац өстәргә:
«Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турындагы геологик мәгълүматтан файдалану тәртибен һәм шартларын билгеләү;»;
б) унберенче абзацны уникенче абзац дип санарга;



2) 7 статьяның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондын булдыру һәм алып бару;»;

3) 14 статьяның беренче өлешендәге өченче абзацында «тау эшләре калдыкларыннан һәм аларга бәйле эшкәртү производстволарыннан» сүзләрен «файдалы казылмалар чыгару калдыкларыннан һәм аңа бәйле эшкәртү производстволары калдыкларыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 18 статьяның бишенче абзацында «үзенең тау эшләре калдыкларыннан һәм шуларга бәйле эшкәртү производстволарыннан» сүзләрен «әлеге җир асты байлыкларыннан файдаланучының эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән файдалы казылмалар чыгару калдыкларыннан һәм аңа бәйле эшкәртү производстволары калдыкларыннан» сүзләренә алмаштырырга;

5) 19 статьяның беренче өлешендә:
а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«җир асты байлыкларыннан файдалану җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылса, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә федераль геологик мәгълүмат фондына һәм аның территориаль фондларына, шулай ук Татарстан Республикасы геологик мәгълүмат фондына җир асты байлыклары хакында геологик мәгълүмат тапшыруны;»;
б) алтынчы абзацта «геологик мәгълүматның федераль һәм территориаль фондларына» сүзләрен «, әгәр җир асты байлыкларыннан файдалану җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылса, федераль геологик мәгълүмат фондына һәм аның территориаль фондларына, шулай ук Татарстан Республикасы геологик мәгълүмат фондына» сүзләренә алмаштырырга;

6) 78 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 86 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү (эчәр сулар белән тәэмин итү яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү

максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгарудан тыш) расланган техник проектлар һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкаруның башка проект документациясе, шулай ук, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органнары белән килештереп, җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүче федераль орган билгели торган, файдалы казылмалар төрләре буенча файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла. Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану расланган техник проектлар һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкаруның башка проект документациясе нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

«Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2001 елның 21 ноябрендәге 1193 номерлы Татарстан Республикасы Законының 38 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 12) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 19-ТРЗ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 170. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 өлешендә:
а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) юридик затның исеме яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);»;
б) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8 статьяның 1 өлешендә «инновация-технология үзәкләрен,» сүзләреннән соң «индустрия паркларын,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 10 статьяның 2 өлешендә «Федераль законның 4 статьясында билгеләнгән шартларга һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 13 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында «читләштерелгән мөлкәт» сүзләрен «читләштерелергә мөмкин булган мөлкәт» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында»

2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә медицина эшчәнлеген лицензияләү;».

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статья белән үз көчләренә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2016 елның 1 августыннан үз көченә керә.

3. 2016 елның 1 августына кадәр юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертү һәм аларны кече һәм урта эшкуарлык субъектлары категорияләренә кертү өчен «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясында («Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) билгеләнгән шартлар кулланыла.

4. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертү өчен «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясында («Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 408-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) билгеләнгән шартларга җавап бирүче юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар аларга кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программалары (ярдәмче программалары) һәм муниципаль программалар (ярдәмче программалар) нигезендә 2016 елның 1 августына кадәр күрсәтелгән ярдәмгә хокукны 2016 елның 31 декабренә кадәр саклап калалар.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 20-ТРЗ



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 171. «Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «җирлекләрнең һәм шәһәр округларының», «(алга таба – җирле үзидарәнең вәкаләтле органы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 3 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы:»;

3) 6 статьяда:

а) 6 өлештә «җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы» сүзләрен «шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлештә «Җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы» сүзләрен «Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 өлештә:

беренче абзацта «Җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы» сүзләрен «Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы»сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) мондый исемлекләргә үзгәрешләр кертү шартнамә нигезендә төзелә торган эконом класслы торакның гомуми санын арттыруга китермәсә, гражданнан аны мондый исемлеккә кертү турында гариза алу;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 26 марты
№ 21-ТРЗ



# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 172. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының уналтынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының уналтынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 183-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

3. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 208-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

4. «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 209-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 212-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

6. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 204-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» 205-5 номер-

лы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 206-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 207-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 201-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 202-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 200-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәреш кертү хакында» 198-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 211-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон таләпләрен бозуларны бетерү хакында Татарстан Республикасы Прокурорының 2016 елның 29 февралендәге 7/2-16-2016/60 номерлы күрсәтмәсе турында.

16. 2015 елда Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре турында доклад.

17. 2015 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында доклад.



18. «Россия Федерациясе Торак кодексының 12 статьясына үзгәреш кертү турында» 982256-6 номерлы федераль закон проекты хакында (куркынычлылыгы югары объектлардан булган лифт җиһазы объектларын тотуга һәм эксплуатацияләүгә карата таләпләр билгеләү өлешендә).

19. «Электр энергетикасы турында» Федераль законның 34 статьясына үзгәреш кертү хакында» 960093-6 номерлы федераль закон проекты турында (җитештерүче компанияләр тарафыннан аларга караган челтәр активларын аерып алуны тыю өлешендә).

20. «Электр энергетикасы турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 963123-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты карары белән электр энергиясен куллануның социаль нормасын кертү өлешендә).

21. «Кулланучылар кредиты (заемы) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

22. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына хезмәт өчен түләүгә кагылышлы өлештә законнар бозган өчен эш бирүчеләрнең җаваплылыгын арттыру мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 983383-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

23. «Россиянең социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы комиссиясе турында» Федераль законның 4 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 992268-6 номерлы федераль закон проекты турында (комиссиянең социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аларга бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне җайга салу мәсьәләләрен карауда катнашу тәртибе хакында).

24. «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 965567-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органына үз вәкаләтләрен ведомство буйсынуындагы оешмаларга тапшыру хокукын бирү хакында).

25. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 965647-6 номерлы федераль закон проекты турында (җирле үзидарә органнарына массакүләм мәгълүмат чараларына карата аерым вәкаләтләр бирү өлешендә).

26. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга федераль дәүләт мәгариф оешмаларында һәм балалар өчен өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый оешмаларда балаларга өстәмә белем бирүне оештыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 984375-6 номерлы федераль закон проекты турында.

27. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 56 статьясына үзгәреш кертү хакында» 945514-6 номерлы федераль закон проекты турында (авыл торак пунктларында урнашкан мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны югары белем алуга максатчан кабул итү турында).

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясына үзгәреш кертү хакында» 958325-6 номерлы федераль закон проекты турында (балигъ булмаганнарның ата-аналары яисә башка законлы вәкилләре балигъ булмаганнарны карау һәм тәрбияләү бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен административ җаваплылыкны үзгәртү өлешендә).

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәреш кертү хакында» 976121-6 номерлы федераль закон проекты турында (кабызылган махсус ут һәм тавыш сигналлары белән транспорт чарасы хәрәкәтен законсыз чикләгән өчен җаваплылык билгеләү өлешендә).

30. «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 977126-6 номерлы федераль закон проекты турында (махсус сайлау счетларына һәм референдумнар счетларына арест сала алуга тыюны билгеләү).

31. «Россия Федерациясе субъектларының иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 984349-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе субъектлары иҗтимагый палаталарын булдыру һәм аларның эшчәнлеге өлешендә).

32. «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» Федераль законның 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.



34. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 978623-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә кагылышлы өлештә).

35. «Россия Федерациясе Салым кодексының 251 һәм 270 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 993570-6 номерлы федераль закон проекты хакында (читкә чыгу туризмы өлкәсендә туроператорлар берләшмәсе оешмаларының табышына салым буенча салым салу тәртибен төгәлләштерү турында).

36. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына таможня кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 981889-6 номерлы федераль закон проекты турында.

37. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 984251-6 номерлы федераль закон проекты турында (куелган таләпләргә җавап бирүен раслау процедурасын узмаган элемтә чараларыннан файдаланган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә)

38. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына адвокатның квалификацияле юридик ярдәм күрсәтү өчен кирәкле белешмәләр җыю хокукын тәэмин итү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 993553-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

39. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

40. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» Федераль законга үзгәреш кертү һәм «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 984699-6 номерлы федераль закон проекты турында (аренда хокукында мәдәни мирас объектларына ия булган һәм аларны саклау эшләренә акчалар керткән затлар тарафыннан мәдәни мирас объектларын хосусыйлаштыру үзенчәлекләре хакында).

41. «Россия Федерациясендә Салым кодексының беренче өлешендәге 11 статьясына үзгәреш кертү турында» 1001467-6 но-

мерлы федераль закон проекты хакында (салым салу максатлары өчен «счетлар (счет)» төшенчәсен төгәлләштерү өлешендә).

42. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 марты
№ 1105-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 173. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп биш елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
19 нчы суд участогына – Борһанова Ирина Ивановнаны;

Татарстан Республикасы Чирмешән суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Вәгыйзова Наилә Мәснәви кызын;

Татарстан Республикасы Теләче суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Салихов Тимур Наил улын.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп ун елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
17 нче суд участогына – Нәбиев Илфир Илдус улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Яруллина Фирания Хәнәфи кызын.

3. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 19 нчы суд участогына Борһанова Ирина Ивановнаның, Татарстан Республикасы Чирмешән суд районы буенча 1 нче



суд участогына Вәгыйзова Наилә Мәснәви кызының, Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 17 нче суд участогына Нәбиев Илфир Илдус улының, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет суд районы буенча 2 нче суд участогына Яруллина Фирания Хәнәфи кызының җәмәгать судьясы вәкаләте чоры 2016 елның 1 маеннан башлана.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 марты
№ 1106-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 174. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 183-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 183-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 марты
№ 1107-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 175. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (183-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (183-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 марты
№ 1108-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 176. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 208-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ш.Ш. Яһудин һәм Р.Г. Ногманов тарафыннан кертелгән «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 208-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 марты
№ 1109-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 177. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (208-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (208-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 марты
№ 1110-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 178. «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 209-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ш.Ш. Яһудин һәм Р.Г. Ногманов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 209-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 марты
№ 1111-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 179. «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (209-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (209-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 11 марты
№ 1112-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 180. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 212-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

